*Нәкый Исәнбәт*

# Мырауҗан агай хәйләсе



*Нәкый Исәнбәт*

# Мыраужан агай хәйләсе

*Художнигы*
*Фәридә Хәсьянова*

*Казан*
*Татарстан китап нәшрияты*
*1989*





Тәрәз төбендә Мыраужан
Утырган кызынырга,
Үзе өйдә, күзе тышта
Багана чыбыгында.
Шул чыбыкка фырлап очып,
Килеп кунды унбер чыпчык.
— И әләли әлли лә,
Тирбәләбез бәлли лә,

И рәхәт тә и кызык,
Тирбәлә тимерчыбык,
Тирбәнүе бик кызык,
Чык-чырык та чык-чырык!
Тәрәз төбендә Мырауҗан
Утыра күзе кызып.
Унбер чыпчык — унбер кош:
— Чык-чырык та чык-чырык!
— Кил, туганым,
уңга чык,
Син, туганым, сулга чык,
Ары чыпчык, бире чыпчык,
Баганадан сикереп чык!
Күтәрелеп унбер чыпчык
Кунышалар тиз-тиз очып.
Күзен алмый шулардан
Карап тора Мырауҗан.
Унбер чыпчык — унбер кош,
Канаты куш, муены буш,
Унбере дә бертигез,
Бик эре дә бик симез.
Болар хәтле кош булмас,
Булса да бергә кунмас,
Болар чык-чык иткәндә
Сайравы ни сандугач!

Нәкъ табада кызган балык
Чык-чырык та чык-чырык;
Тапсаң иде хәйләсен,
Тоталсаң иде чыгып!
Я ичмасам талпынып
Өзелми дә шул чыбык!
Менә тотсам мин чыгып,
Булыр сезгә чык-чырык!
Шунда тагын унбер
чыпчык
Кунышалар тиз-тиз очып...
Тирбәлә тагын чыбык,
Көлешәләр — чык-чырык!
Әйткән кебек Мырауга:
— Көчең җитсә, тот чыгып!

Торды Мырау, түзмәде,
Абау яна күзләре:
— Мин, ди, анда чыкмасам,
Үзләрен, ди, тотмасам,
Унбер чыпчык — унбер кош —
Унберен дә йотмасам,
Артымда йөртмим койрык,
Алдымда йөртмим мыек,

Парикмахерга керәм дә
Ташлатам барын кырып!
Ул шулай дип ант итә,
Күзе янып ялт итә,
Арттан аның койрыгы
Уйный — ялт та йолт итә.
Күреп ала ул шул чак,
Аунап ята бер курчак.
Ул курчакның янында
Киеме бар бер кочак.
Ул андамы, ул анда —
Ни генә юк шул анда!
Менә чалбар буй-буйлы,
Менә камзул юл-юллы,
Менә бәрхет түбәтәй,
Кисәң булмас бәләкәй...
Моны күргәчтен мырлап
Җибәрде Мырау җырлап:
— Безнең хуҗа
Фәрхеттин,
Түбәтәе бәрхеттин,
Шундый түбәтәйләр
кигәч,
Ник булмам мин
Фәрхеттин?..

Мырр-мырый,
мырр-мырый!
Әй унбер кош, унбер кош,
Акылы буш, муены буш,
Сез булсагыз унбер кош,
Миндә дә бар унбер теш,
Сез торыгыз бер карап,
Мин күрсәтим маскарад!

Мырр-мырый,
мырр-мырый!
Озак эшме киенү?
Кирәкми тик иренү.
Ике минут, өч минут —
Үтте микән биш минут?
Менә кызыл итектән
Мырау чыкты ишектән.
Чалбарыдыр — буй-буйлы,
Камзулыдыр — юл-юллы,

Түбәтәе бәрхеттин —
Чын булган бу Фәрхеттин!
Менә сиңа ярминкә,
Кулларында тәлинкә,
Ярма салган эченә,
Чыпчыкларга китерә.
Үзе шул чак елмайган,
Әйтмәссең бу —
Мыраужан,
Авызы-башы очлайган,
Иреннәре былчайган.
Ул — басып барышлары,
Күрсәң кыланышлары!
Эндәшә йомшак кына,
Хәтфәдер тавышлары:
— Хуш килдегез, кошларым,
Кунакларым, дусларым,
Сез бит нәни чыпчыклар,
Иң файдалы кошчыклар,
Сез кырасыз чебенне,
Сайрашасыз күңелле,
Якын иткәч сез безне
Мин дә бер сыйлыйм сезне:
Менә сиптем ярмалар,
Монда сезгә бар да бар,
Сез төшегез ярмага
Җыелмасын каргалар.
Чеп-чеп-чеби, чеп-чеби,
Бушка сайрау эшмени?

Шулай дигән булып ул,
Ярманы бик сипте мул.
Әмма ләкин сипсә дә,
Төшәрләр дип көтсә дә,
Нигәдер эш бик дымык,
Селкенми тора чыбык,
Анда кунган унбер
чыпчык.
Ник берәүсе төшсен очып!
Аптырый бит Мырауҗан,
Тыелалмый сораудан:
— Тын калдыгыз сез нидән?
Әллә куркасыз миннән?
Қуркасыз икән миннән —
Мин, ди, читкә чигенәм...
Чеп-чеп-чеби, чеп-чеби,
Юктан өркү эшмени?
Шунда әйтә бер чыпчык,
Қырыйдагы зур чыпчык:
— Әй, абзыем Фәрхеттин,
Түбәтәең бәрхеттин,
Чалбарың да буй-буйлы;
Қамзулың да юл-юллы,
Қүлмәгең дә бик тәти,
Укалыдыр хәтта ки.



Шунсы гына тик кызык:
Койрыгың калган чыгып.
Ул койрыкны чалбарга
Булмадымыни тыгып?
Унбер чыпчык — унбер кош,
Канаты буш, муены буш,
Әй көләләр чык-чырык,
Тирбәлә бөтен чыбык:
— Карагыз нинди кызык,
Чык-чырык та чык-чырык!
Койрыгы калган чыгып,
Чык-чырык та чык-чырык!
Иң кызыгы — шул кызык,
Чык-чырык та чык-чырык!
Ул койрыкны чалбарга
Булмыймыни кыстырып?

— Хур булдым! —
Диде Мырау,—
Котылыйм өйгә кереп!
Борылган гына иде,
Чыпчыклар үлә көлеп.
Көлмәслек кенәмени?
Койрыгы чыкты килеп.
Койрыгы койрык булса!
Селкенә сиртмә кебек.
Уңга да карый борып,
Сулга да карый борып,
Ул кая куйсын аны?
Үзенә үскән койрык!

15 тиен

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен

*Исанбет Наки Сиразеевич*

# *Приключения Мураузяна*

Стихотворение

*(на татарском языке)*

Редакторы *Л. Нәҗмиева*
Художество редакторы *Т. Хаҗиәхмәтов*
Техник редакторы *Л. Тилк*
Корректоры *М. Кәримова*

ИБ № 5525

Җыярга тапшырылды 27.02.89. Басарга кул куелды 20.04.89. Форматы $60 \times 90^1/_{16}$. 100 гр. офсет кәгазе № 1. «Литературная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 0,75. Шартлы буяу-оттиск 1,0. Нәшер-хисап табагы 1,59. Тиражы 150 000 экз. Заказ Б-133. Бәясе 15 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство.
420084. Казань, ул. Баумана, 19.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

ББК 84 (2Р-Тат)-5
И 85

И $\frac{4803010200-153}{М\ 132(03)-89}$ 159—89

ISBN 5--298—00381--8

© Рәсемнәр.
Татарстан китап нәшрияты, 1989.